**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
29 декабрь 2018 ел № 157

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге «Физик затлар милкенә салым турында»гы 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге «Физик затлар милкенә салым турында» гы 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 абзац 3 пунктчасының 2 пунктындагы "бер торак бина (Торак йорт)" сүзен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 пунктның 3 пунктчасындагы 1 абзацында "торак йортлардан соң «торак йортларның өлешләреннән" сүзләрен өстәргә;»;

1.3. киләсе эчтәлектәге 3.1 пункты белән тулыландырырга:

«3.1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган бер ата-ана (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә.

Салым ташламасы салым салуның һәр төре буенча салым салынучы объектның бер объектына карата бирелә: салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган фатир (бүлмә) яки торак йорт (торак йорт).

Салым ташламасы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә даими яшәүче (теркәлгән) салым түләүчеләргә бирелә.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым

ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләге белән салым бирү турында гариза тапшыралар

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ га урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина